Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл жирлеге советы
423066 **Яңа Кармәт** авылы
Муса Җәлил урамы,15а нче йорт
тел. 4-92-33 факс

Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт
Яңа Кармәт авылы , 4203066

Совет Новокиреметского сельского поселения Аксубаевского муниципального района
42306 с.Новая Киреметь
улица Мусы Джалиля, д.15а
тел. 4-92-33 факс

ул. Мусы Джалиля, д 15а,
с.Новая Киреметь, 423066

Тел. (8-84344-4-92-33) ОГРН 1021605359709,
ОКПО 04311599, ИНН/КПП 1603001197/160301001
E-mail*: Nkir.Aks@tatar.ru*

# КАРАР

№10

2023 елның 1 нчы декабре

“Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Рус Кармәт авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында”

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Яңа Кармәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып.

Карар итте:

1. 2023 елның 14 декабрендә Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Рус Кармәте авылында гражданнар җыенын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2.1. Рус Кармәт авылы гражданнары җыенының 22.11.2023 no 2 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2.2. 2024 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Рус Кармәт авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 550 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, көндезге уку йортында катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан һәм алынган акчаларны сорауларны хәл итүгә юнәлтүдән тыш түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм тоту:

- кышкы вакытта Рус Кармәт авылы эчендә юлларны тоту, урамнарны кардан чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

Рус Кармәт торак пункты урамнары буенча вак таш белән капланган юллар төзү (сатып алу, ташу, салу, вак таш, туфракны тигезләү, ком һәм туфрактан нигез салу, килешү буенча эш өчен түләү) ;

“ӘЙЕ” “ ЮК” “ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

4. Җыеннар үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Рус Кармәте авылы, Новостройка урамы 29нчы йорт адресы буенча урнашкан Рус Кармәт авыл мәдәният йорты .

5. Җыенны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

6. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

7. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров